КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 сентябрь г.Казань № 1185

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2018 ел, 12 июль, 566 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 884 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1138 нче; 2020 ел, 17 март, 192 нче; 2020 ел, 14 июль, 590 нчы; 2020 ел, 5 август, 656 нчы; 2020 ел, 28 декабрь, 1203 нче; 2021 ел, 7 октябрь, 959 нчы; 2021 ел, 7 декабрь, 1180 нче; 2022 ел, 12 март, 224 нче; 2022 ел, 31 октябрь, 1161 нче; 2023 ел, 16 июнь, 723 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы Президентының «Дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасы турында» 2005 елның 28 апрелендәге ПУ-147 номерлы Указы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы – Татарстан Республикасында мәдәният, сәнгать, кинематография өлкәсендә дәүләт сәясәтен уздыручы

һәм дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы.»;

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«<*> Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

3.3 пунктта:

3.3.8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.8. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган республика башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларына ирешүне тәэмин итә;»;

3.3.27 пунктчада «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән башкарма органнары» сүзләрен «башкарма хакимиятнең бүтән республика органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                 А.В.Песошин